# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 апреля 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 27 декабря 2004 года № 69-ЗРТ «О государственной поддержке развития жилищного строительства в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 12 (II часть); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I часть); 2013, № 7; 2014, № 6 (II часть); 2015, № 3) следующие изменения:

1) пункт 3 статьи 5 изложить в следующей редакции:

«3) граждане, включенные в сводный реестр специализированной организации, а также граждане, заключающие трудовые договоры с юридическими лицами, взаимодействующими на договорной основе со специализированной организацией;»;

2) статью $6^1$ изложить в следующей редакции:

«Статья $6^1$. **Предоставление земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, для жилищного строительства**

1. Для осуществления на территории Республики Татарстан жилищного строительства земельные участки, находящиеся в государственной или муниципальной собственности, могут быть предоставлены однократно бесплатно в собственность граждан, участвующих в социальной ипотеке, реализуемой в рамках настоящего Закона, из числа зарегистрированных по месту постоянного проживания в сельских поселениях молодых специалистов, работников бюджетной сферы и сельскохозяйственной отрасли для осуществления индивидуального жилищного строительства или ведения личного подсобного хозяйства в случае, если они заключили договоры, предусматривающие инвестиции, со специализированной организацией, осуществляющей деятельность в соответствии с основными направлениями, предусмотренными статьей 9 настоящего Закона.

2. В целях обеспечения жилыми помещениями категорий граждан, указанных в пункте 3 статьи 5 настоящего Закона, земельные участки, находящиеся в государственной или муниципальной собственности, могут быть предоставлены в безвозмездное пользование специализированным организациям – республиканским некоммерческим организациям в соответствии со статьей $39^{10}$ Земельного кодекса Российской Федерации.

3. Перечень документов, необходимых для принятия решения о бесплатном предоставлении гражданам, участвующим в социальной ипотеке, земельных участков, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в рамках настоящего Закона, определяется Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

3) в статье 9:

а) в пункте 9 слово «собственности» исключить;

б) пункт 11 после слов «инвестиционной программой» дополнить словами «специализированной организации»;

в) дополнить пунктом $11^{1}$ следующего содержания:

«$11^{1}$) формируют и ведут сводный реестр граждан, нуждающихся в государственной поддержке в улучшении жилищных условий, на основании данных учета, осуществляемого государственными органами, органами местного самоуправления, организациями всех форм собственности, в соответствии с инвестиционной программой специализированной организации;».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
14 мая 2018 года
№ 31-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелгән гражданнар, шулай ук махсуслаштырылган оешма белән үзара шартнамә нигезендә эшләүче юридик затлар белән хезмәт шартнамәләре төзүче гражданнар;»;

2) $6^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$6^1$ статья. **Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен торак төзелеше өчен бирү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре әлеге Закон кысаларында гамәлгә ашырыла торган социаль ипотекада катнашучы, даими яшәү урыны буенча авыл җирлекләрендә теркәлгән яшь белгечләр, бюджет өлкәсе һәм авыл хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләре арасыннан булган гражданнарның милкенә, алар үз эшчәнлеген әлеге Законның 9 статьясында каралган төп юнәлешләр нигезендә башкаручы махсуслаштырылган оешма белән инвестицияләр каралган шартнамәләр төзегән очракта, индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бер мәртәбә түләүсез бирелергә мөмкин.

2. Әлеге Законның 5 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән категориядәге гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү максатларында дәүләт милкендәге

яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясы нигезендә махсуслаштырылган оешмаларга – республиканың коммерциягә карамаган оешмаларына түләүсез файдалануга бирелергә мөмкин.

3. Әлеге Закон кысаларында социаль ипотекада катнашучы гражданнарга дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен түләүсез бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.»;

3) 9 статьяда:

а) 9 пунктта «милекчелек» сүзен төшереп калдырырга;

б) 11 пунктта «белешмәләре нигезендә,» сүзләреннән соң «махсуслаштырылган оешманың» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $11^{1}$ пункт өстәргә:

«$11^{1}$) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар гамәлгә ашыра торган исәпкә алу белешмәләренә таянып, махсуслаштырылган оешманың инвестиция программасы нигезендә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ гражданнарның җыелма реестрын төзиләр һәм алып баралар;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 31-ТРЗ